| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Шланга авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 сентябрь 2024 ел № 40/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 15.11.2019 елның 45/3 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 15.11.2019 елның 45/3 номерлы «физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (22.05.2020 № 49/5, 15.11.2022 №21/3 20.10.2023 №31/2 редакциядә) 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:
"- РФ Салым кодексының 378.2 маддәсе 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1 000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата 1,2 % ;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге Уставы нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы И.И.Якупов